Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

07.10.2021 Менделеев шәһәре № 694

“Салым һәм салым булмаган бурычларны
киметү буенча ведомствоара баланс комиссиясе
составын һәм нигезләмәсен раслау турында”

Менделеев муниципаль районында салым һәм салым булмаган бурычларны киметү буенча алга таба эшне, шулай ук икътисадтагы тискәре тенденцияләрне җиңеп чыгуны тәэмин итү максатларында Татарстан республикасы Менделеев муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Салым һәм салым булмаган бурычларны киметү буенча ведомствоара баланс комиссиясе нигезләмәсен расларга (1 нче кушымта).
2. Салым һәм салым булмаган бурычларны киметү буенча ведомствоара баланс комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта)

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеев муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, эшмәкәрлекне үстерү буенча урынбасары И. С. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.И. Беляев

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Менделеев
муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның  7 нче октябрендәге  694 нче номерлы
карары белән расланган

**Менделеев муниципаль районында салым һәм салым булмаган бурычларны киметү буенча ведомствоара баланс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Беляев Р.И. | комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Гиззатуллин И.С. | комиссия рәисе урынбасары Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Гараева Л.А. | комиссия сәркәтибе, Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы Башкарма комитеты икътисад, сәнәгать һәм эшкуарлыкка ярдәм итү бүлеге башлыгы |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Алгулатов К.Р. | Менделеев районы буенча Россиянең ЭЭМ бүлегенең ЮХИДИ булеге башлыгы (килешү буенча) |
| Антоновская Н.И. | Менделеев муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Ахмадиева Р.Х. | «Бондюжский» ТИҮ рәисе (килешү буенча) |
| Ахметшина М.Р. | Менделеев муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе (килешү буенча); |
| Григорьев М.В. | Менделеевск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча); |
| Егоров И.В. | Менделеев районы буенча Россиянең ЭЭМ бүлеге башлыгы урынбасары –полиция башлыгы (килешү буенча) заместитель начальника Отдела МВД России по |
| Загрутдинова Г.А. | «Карповец» ТИҮ рәисе (килешү буенча) |
| Закирова Л.Р. | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 9 нчы районара инспекциясе вазифаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Захарян А.А. | Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазифаларын башкаручы |
| Сафаргалин А.Н. | Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазифаларын башкаручы |
| Сафиуллина Л.И. | ТР буенча Менделеевс РОСП УФССП РФ вазифаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча); |
| Козырева Ф.В. | Менделеев муниципаль районында хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Кузнецова Е.М. | «Поселок»ТИҮ рәисе (килешү буенча); |
| Мухамадеева Е.Н. | ДКҮ «Менделеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге " директоры (килешү буенча); |
| Талыпова А.А. | «Химик» ТИҮ рәисе (килешү буенча); |
| Царева Е.С. | Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы Башкарма комитеты юридик бүлеге башлыгы |
| Фарухшин И.И. | Менделеев муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы |

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Менделеев
муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 7 нче октябрендәге 694 нче номерлы
карары белән расланган

Салым һәм салым булмаган бурычларны киметү буенча ведомствоара
баланс комиссиясе нигезләмәсе

Менделеев муниципаль районы салым һәм салым булмаган бурычларны киметү буенча ведомствоара баланс комиссиясе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары (алга таба – федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары) һәм җирле үзидарә органнарының үзара килешеп эшләүләрен тәэмин итү, салым һәм салым булмаган бурычларны киметү һәм икътисадтагы тискәре тенденцияләрне җиңү өчен оештырылган коллегиаль ведомствоара орган булып тора.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, Менделеевск муниципаль районының норматив-хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна
4. Комиссиянең төп функцияләре һәм бурычлары

- бурычлылар тарафыннан салым һәм салым булмаган түләүләрне вакытында түләүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар эшләү ;

- Менделеев муниципаль районы территориясендә урнашкан аерым хуҗалык итүче субъектларның бөлгенлеккә төшүен кисәтү чаралары турындагы тәкъдимнәрне анализлау, шулай ук әлеге хуҗалык итүче субъектларга карата тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны карауга кертү;

Комиссия

- үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының җитәкчеләрен һәм башка вазыйфаи затларын, шулай ук эшче төркемнәр (Советлар, комиссияләр), хуҗалык итүче субъектларның җитәкчеләрен чакырырга;;

- комиссия ачыклаган бозуларны бетерү максатларында закон нигезендә карарлар кабул итү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына мәгълүмат җибәрергә ; ;

- Комиссия эшенә ярдәм итү өчен дәүләт күзәтчелеген һәм контролен гамәлгә ашыручы хокук саклау органнарын җәлеп итәргә

- кирәк булганда, Комиссия компетенциясенә керүче карарлар һәм башка материалларны әзерләүдә катнашу өчен федераль һәм республика башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, хуҗалык итүче субъектларның белгечләрен җәлеп итәргә;

- Комиссия эшчәнлегенең аерым юнәлешләре буенча эшче төркемнәр булдырырга хокуклы

5. Комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе һәм комиссия әгъзалары составында төзелә, алар аның эшендә җәмәгать башлангычларында алмаштыру хокукыннан

башка гына катнаша.

6. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма айга кимендә бер тапкыр уздырыла. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

8. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, комиссия рәисе кул куя.

9. Комиссия Рәисе:

- комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота;

- комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә, Комиссия утырышларын үткәрә һәм аларга рәислек итә;

- Комиссия эшчәнлеген тәэмин итүче карарлар кабул итә.

10. Комиссия рәисе вакытлыча булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары, яисә комиссия рәисе карары буенча комиссиянең башка әгъзасы башкара.

11. Комиссия сәркәтибе утырышлар беркетмәләрен алып бара, комиссия кабул иткән карарларның үтәлеше турында мәгълүмат әзерли.

12. Комиссия эшчәнлеген оештыру, техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.